Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең
Урта Ушма поселогында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

13 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23.1нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенец урта Ушма торак пунктында гражданнар җыены үткәрелеп карар итте:

1. 2023 елда Балтач районы Кече Лызи авыл җирлегенең Урта Ушма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булганнарга 400 сум күләмендә үзара салым кертергә, үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән: 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәклләрдән, сәләтсез гражданнардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыныц тол хатыннарыннан, өлкән яшьтәге ялгыз пенсионерлардан, үз – үзләренә хезмәт күрсәтә алмаган гражданнардан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче тулы булмаган куп балалы гаилә әгъзаларыннан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш..

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Лесная урамындагы юлны норматив хәлгә китерү.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматыныц рәсми порталында pravo.tatarstan.ru.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А. С.Исмагилов